**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 июнь № 370

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы, 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче, 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче, 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы, 2011 ел, 05 март, 177 нче, 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче, 2012 ел, 19 июнь, 524 нче, 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче, 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче, 2014 ел, 21 апрель, 262 нче, 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы, 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче, 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы, 2015 ел, 7 август, 575 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларына законнарда билгеләнгән тәртиптә республика (төбәк) дәүләт төзелеш күзәтчелеген (алга таба – республика дәүләт төзелеш күзәтчелеге) гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.».

1.4 пунктта «законнарда билгеләнгән тәртиптә банк учреждениеләрендә ачыла торган бюджет, исәп һәм бүтән счетлар» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә казначылык органнарында ачылган шәхси счетлар»;

1.6 пунктка «һәм физик затлар» сүзләрен өстәргә;

2 бүлеккә «республика дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда» сүзләрен өстәргә;

3 бүлектә:

3.1 пунктта «шул исәптән өченче һәм дүртенче класслардагы гидротехник корылмалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Архив эше белән идарә итү вазыйфаларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе тарафыннан (01.15.03).»;

3.3 пунктның сигезенче абзацында «кисәтүе буенча һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 пунктның тугызынчы абзацын төшереп калдырырга;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, төзекләндергәндә, республика дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында бозуларны кисәтү буенча чаралар эшләүдә катнаша;

Инспекция күзәтчелегендә булган төзелә торган, шулай ук төзелеше тәмамланган һәм билгеләнгән тәртиптә кулланылышка тапшырылмаган объектлардагы аварияләр сәбәпләрен карап тикшерү буенча комиссия эшендә катнаша;

дәүләт статистикасы органнарына һәм Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар, проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары таләпләренә туры килүе турында билгеләнгән тәртиптә бирелгән бәяләмәсез (алга таба – туры килү турында бәяләмә) кулланылышка кертелгән республика дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырыла торган объектлар турында мәгълүмат тапшыра;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Инспекция Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге очракларда законнарда билгеләнгән тәртиптә республика дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыра:

проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза (дәүләтнеке булган яки дәүләтнеке булмаган) үткәрелергә тиеш яисә үрнәк проект документлары яисә аның уңай экспертиза (дәүләтнеке булган яки дәүләтнеке булмаган) бәяләмәсе алган башка төргә әйләндерелгәне булган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, әлеге кодексның 54 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән объектлардан тыш, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеш нигезендә алынган эш башлау турында хәбәрдән алып туры килү турында бәяләмә бирелгән көнгә кадәр;

капиталь төзелеш объектларын төзекләндергәндә, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның

ышанычлыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка сыйфатларына кагыла торган эшләр үткәргәндә, әгәр капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүне гамәлгә ашыруга проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза (дәүләтнеке булган яки дәүләтнеке булмаган) үткәрелергә тиеш булса, әлеге кодексның 54 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән объектлардан тыш, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә әлеге кодексның 52 статьясындагы 5 өлеш нигезендә алынган эш башлау турында хәбәрдән алып туры килү турында бәяләмә бирелгән көнгә кадәр.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктта:

4.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.1. Тикшерүләр үткәрергә:

проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза (дәүләтнеке булган яки дәүләтнеке булмаган) үткәрелергә тиеш яисә үрнәк проект документлары яисә аның уңай экспертиза (дәүләтнеке булган яки дәүләтнеке булмаган) бәяләмәсе алган башка төргә әйләндерелгәне булган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, әлеге кодексның 54 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән объектлардан тыш, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеш нигезендә алынган эш башлау турында хәбәрдән алып туры килү турында бәяләмә бирелгән көнгә кадәр;

башкарылган эшләрнең, кулланылган төзелеш материалларының һәм мондый эшләр нәтиҗәләренең техник регламентлар, проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары таләпләренә туры килүенә;

төзелешкә рөхсәт булуга;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләр таләпләрен үтәүгә.

Түбәндәгеләрне үтәү тикшерелергә тиеш:

төзегәндә – җир кишәрлеген әзерләүне гамәлгә ашыруга һәм җир эшләрен, фундаментларны, җир асты һәм җир өстендәге төзелмәләрне, инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен (шул исәптән эчке һәм тышкы челтәрләрне), инженерлык системаларын һәм җиһазларын монтажлау буенча эшләрне башкаруга таләпләр;

төзекләндергәндә, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның ышанычлыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка сыйфатларына кагыла торган эшләр үткәргәндә - капиталь төзелеш объектының, аның өлешләренең параметрлары үзгәргәндә, шулай ук капиталь төзелеш объектының төп төзү конструкцияләрен алыштырганда һәм (яки) торгызганда (мондый конструкцияләрнең аерым элементларын нәкъ шундый ук яки мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшыртачак бүтән элементларга алыштырудан һәм (яки) әлеге элементларны торгызудан тыш) капиталь төзелеш объектын төзекләндерү өчен әзерләү буенча эшләр башкаруга таләпләр, шулай ук линия объектларының яки аларның участокларының (өлешләренең) параметрларын мондый объектларның классы, категориясе һәм (яки) беренчел билгеләнгән эшләү күрсәткечләре (куәте, йөк күтәрүчәнлеге һәм башкалар) үзгәрүгә китерәчәк яки мондый объектларның бүлеп бирелгән чикләрен һәм (яки) саклау зоналарын үзгәртү

таләп ителәчәк үзгәртү эшләренә таләпләр.»;

4.1.2 пунктчага «дәүләт төзелеш күзәтчелеге» сүзләреннән соң «вазыйфаи вәкаләтләрен башкару кысаларында» сүзләрен өстәргә;

4.1.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.3. Төзелешне, төзекләндерүне гамәлгә ашыручы техник заказчыдан, төзүчедән яки бүтән заттан түбәндәгеләрне таләп итәргә:

төзелешне, төзекләндерүне гамәлгә ашырырга җәлеп ителгән затлар белән шартнамәләрне күрсәтүне;

капиталь төзелеш объектларының иминлегенә йогынты ясый торган аерым эш төренә яки төрләренә рөхсәт турында таныклык күрсәтүне;

проект документларын тулы күләмдә кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында күрсәтүне;

башкарылган эшләргә һәм кулланылган төзү материалларына тикшерүләр, сынаулар, экспертизалар үткәрүне, әгәр алар төзелеш контроле үткәрүне таләп итеп тә, ул гамәлгә ашырылмаган булса;

башкарылган эшләр нәтиҗәләрен, башкарма документларны, гомуми һәм (яки) махсус журналларны, эшләрне, корылмаларны, инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен, кулланыла торган төзү материаллары үрнәкләрен (пробаларын) таныклау актларын»;

4.1.5 пунктчаның икенче абзацында «Күрсәтелгән акча республика дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча өстәмә чараларны финанслау өчен Татарстан Республикасы Финаслар министрлыгының Казначылык департаменты счетына күчерелә» җөмләсен «Күрсәтелгән акча республика дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча өстәмә чараларны финанслау өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә бюджет керемнәре администраторының шәхси счетына күчерелә» җөмләсенә алмаштырырга;

4.1.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.6. Төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү үткәрергә, төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар, проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының Инспекциянең аерым бланкларында башкарылган файдаланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән җиһазлау таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү хакында яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар кабул итәргә.

Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү үткәрергә, зарур булганда, төзелештә катнашучыларны, проект оешмасы вәкилләрен, капиталь төзелеш объектын куркынычсыз кулланылышка кертүгә вәкаләтле орган, баланс тотучыны, ведомство тикшерүе органнарын, шулай ук белгечләрне, экспертларны җәлеп итәргә.»;

4.1.10 пунктчасына «тикшерүдә тотучы органнар» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

4.1.11 пунктчасына «вазыйфаи затлар» сүзләреннән соң «физик затлар» сүзләрен өстәргә;

4.1.14 пунктчасында «һәм чит кешеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.28-4.1.29 пунктчалар өстәргә:

«4.1.28. Ведомство бүлекләрен гамәлгә куярга, алар белән бүләкләү турында

карарлар кабул итәргә һәм дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш контроле инспекциясе хезмәткәрләрен, эшләүчеләрен бүләкләүнең башка төрләрен кулланырга.»;

«4.1.29. Законнар нигезендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерергә, алар буенча кирәкле чаралар күрергә, Инспекция компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итүләр алып барырга.».

5 бүлекнең 5.3 пунктындагы унбишенче абзацка «вазыйфаи регламентлар» сүзләреннән соң «(инструкцияләр)» сүзләрен өстәргә;

6 бүлекнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Инспекция мөлкәтен, карап тотуны һәм финанс ресурсларын формалаштыру чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты чаралары тора, шул исәптән башкарылган эшләргә һәм кулланылган төзү материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатория һәм бүтән сынаулар чыгымнарын каплау өчен кергән акча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков